**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

Министерство образования и науки Республики Татарстан

МКУ «Отдел образования Исполнительного комитета Актанышского муниципального района РТ»

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| рук. ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор |
| Исрафилова А.Р. | Сaетова Г.М. | Ахметова Г.Р. |
| ____________ | ____________ | ____________ |
| Протокол №1 | ~~Протокол №1~~ | Приказ № |
| от "24" 08.2023 г. | от "28" 08 2023 г. | от "29" 08.2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета

«Родной (татарский) язык»

для 5-9 классов основного общего образования

для образовательных организаций с обучением на родном (татарском) языке

на 2023-2024 учебный год

Составитель:
учитель родного (татарского) языка и
родной (татарской) литературы
Исрафилова А.Р.

2023

**Туган (татар) тел фәнен федераль эш программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр**

**5 - 9 сыйныфлар**

Дәреслекләр, авторлар:

Туган тел (татар теле). 5 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов; [рәссамы Диләрә Нәүрузова]. – Казан, 2022. – 168 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 5 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы Диләрә Нәүрузова]. – Казан, 2022. – 164 б.: рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 6 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 172 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 6 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 192 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 7 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 120 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 7 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 176 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 8 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 144 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 8 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 144 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 9 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.

М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 116 б. : рәс. б-н.

Туган тел (татар теле). 9 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2022. — 148 б. : рәс. б-н.

**Методик тәкъдимнәр**
**(дәреслекнең структурасы, игътибарга алынырга тиешле төп моментлар)**

5-9 сыйныф дәреслекләре ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала.Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш» темалары, икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темалары урнаштырылды.

Дәреслекләр ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләр) үз эченә ала. Туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган материал зәңгәрсурамка белән бирелде. База өлешен өйрәнүче укучыларга да, балаларның белем дәрәҗәләрен, мөмкинлекләрен исәпкә алып, әлеге биремнәр тәкъдим ителергә мөмкин. База һәм тирәнтен өйрәнү өчен булган материалның бер дәреслектә бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләү мөмкинлеге тудыра. Дәреслекләрдә аерым тема эчендә ике юнәлеш өчен дә бер тексттан алынган берничә өзек кулланыла. Бу база өлешен өйрәнүче укучыларда текстның дәвамын уку теләге тудыру өчен дә отышлы. Бишенче сыйныфтан башлап тугызынчы сыйныфка кадәр сәгатьләр саны барлыгы **68 (рус мәктәпләренең татар балаларына) / 102 (телне тирәнтен өйрәнүче татар балаларына)** дип күрсәтеп барылды.

Темаларның төзелешенә килгәндә  һәр тема бертөрле калыпка салынды. Бер тема берничә дәресне үз эченә алырга мөмкин. Темаларның, дәресләрнең эчтәлеге түбәндәге тәртиптә эшләнде:

1) Дәрес гадәттәгечә психологик уңай халәт тудыру  белән башланып китә. Укучылар ярдәме белән дәреснең темасы билгеләнә. Дәреснең максаты, бурычлары ачыклана.
2) 5-7 сыйныфларда темага караган һәр дәрестә эпиграф, төрле ситуацияләр белән эшләү (аерым әсәрләрдән алынган өзекләр, мәкальләр, табышмаклар, ребуслар һ.б.) дәресләрнең башлам өлешендә, йомгаклаганда, зур бер теманы тәмамлаганда мөстәкыйль фикер әйтергә, теманы ныгыту, нәтиҗә ясарга өйрәтү максатыннан кертелде.
3) Грамматик материал өйрәнелә. Сорауларга җавап бирү, рәсемнәр белән эшләү, фикер алышу (парларда эш), грамматик мәгълүматны ныгыту максатыннан башкарыла.
5) Дәреслекләрдә яңа теманы ныгыту өчен биремнәр, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бәйле эш төрләре тәкъдим ителә.
6) Теманы йомгаклау өчен күнегүләр, логик биремнәр, рәсемнәр, кызыклы эш төрләре бирелә. Чирек ахырында тестлар, кабатлау өчен сөйләм эшчәнлеге төрләре (ишетеп аңлау, уку, сөйләү, язу) белән бәйле күнегүләр, төрле биремнәр, анализлар тәкъдим ителә.